Татарстан Республикасы  Әлки муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2019 нчы елның 12 нче апреле 240№

Әлки муниципаль районы Советының
2016 нчы елның 26 нчы апрелендагы
99 нче номерлы «Әлки муниципаль районының
Иҗтимагый советы турында Нигезләмә»
карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»,  2008 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законнары, 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре» Россия Федерациясе Президентының Указы, 2018 нче елның 24 нче сентябрендәге Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе утырышы беркетмәсенең 4.3 пункты  һәм 2019 нчы елның 11 нче февралендәге  Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы утырышы беркетмәсенең  5.1. пунктының 1 пунктчасы нигезендә, Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 22 августындагы 45 номерлы карары белән расланган Әлки муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге пункт өстәргә:

«- коррупциягә каршы көрәштә үз вәкаләтләре чикләрендә катнашу»;

- 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге пункт өстәргә:

"- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыруда катнаша".

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы Никошин А.Ф.